**5 нче сыйныф**

**Татар әдәбиятыннан тест**

**Фатих Кәримнең «Кыр казы», «Ватаным өчен» шигырьләре**

**1.Фатих Кәрим кайда туган?**

а) Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында;

ә) Бәләбәйдә;

б) Казан шәһәрендә.

**2.Бөек Ватан сугышы елларында ул кайда була?**

а) 1942—1945 нче елларда фронтның алгы сызыгында сугыша;

ә) сугышка бармый;

б) заводта эшли.

**3.Фатих Кәрим кайда һәлак була?**

а) Германиядә;

ә) Көнчыгыш Пруссиядә;

б) Венгриядә.

**4. Автор кыр казыннан нәрсә сорый?**

а) туган иленә сәлам әйтүен;

ә) туган иленнән хат китерүен;

б) җыр язу өчен бер каурыен бирүне.

**5. Шигырьдә кайсы ел фасылы сурәтләнә?**

а) кыш;

ә ) көз ;

б) яз.

**6. Ф. Кәримнең бу шигъри юллары кайсы шагыйрьнең шигыре белән аваздаш?**

***Бөек җыр ул — бөек Ватан өчен***

***Сугыш кырларында үлүе.***

а) Муса Җәлилнеке белән;

ә) Сибгат Хәкимнеке белән;

б) Габдулла Тукай шигыре белән.

**7. Шигырьдә хат кемгә языла?**

а) әнисенә;

ә) хатынына;

б) туган илгә.

**8. Шагыйрь нигә үлем турында уйлана?**

а) ул фронтта алгы сызыкта йөри;

ә) ул авырый;

б) ул яшәүдән туйган.

**9. Фатих Кәрим Туган илен яратамы?**

а) ул чит илгә китәргә тели;

ә) әйе, ярата;

б) юк, яратмый.

**Ачкыч**

1. **А**
2. **А**
3. **Ә**
4. **Б**
5. **Б**
6. **А**
7. **Б**
8. **А**
9. **Ә**

# Бәяләү

**8-9 балл – “5”ле**

**6-7 балл – “4”ле**

**4-5 балл – “3”ле**